# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Физик культура һәм спорт турында”**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 30 маенда
кабул ителде

**1 статья**

“Физик культура һәм спорт турында” 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш), 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 27 декабрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 9 пунктында “физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен үткәрү, норматив-хокукый җайга салу, дәүләт хезмәтләрен күрсәтү (спортта допинг булдырмауны һәм аңа каршы көрәшне кертеп) һәм дәүләт мөлкәтенә идарә итү вазыйфаларын гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органының (алга таба – физик культура һәм спорт өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы),” сүзләрен “физик культура һәм спорт өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының,” сүзләренә алмаштырырга;

2) 10 статьяда:
а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“3. Гомумроссия спорт федерациясенең структур бүлекчәсе (республика бүлекчәсе) булып торган республика спорт федерациясе юридик зат хокукларын алмаска да мөмкин.”;
б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“4. Физик культура һәм спорт өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы Татарстан Республикасы территориясендә спортның бер төре буенча бары тик бер генә республика спорт федерациясен аккредитацияләргә бирергә тиеш. Спортның мондый төре (төрләре) буенча гомумроссия спорт федерациясе булган очракта, спортның шул ук төре (төрләре) буенча республика

спорт федерациясе сыйфатында аккредитацияләнгән республика иҗтимагый оешмасы шундый гомумроссия спорт федерациясе әгъзасы булырга тиеш.

Гомумроссия спорт федерациясенең республика иҗтимагый оешмаларын яисә аларның структур бүлекчәләрен (республика бүлекчәләрен) республика спорт федерацияләре статусын бирү өчен дәүләт тарафыннан аккредитацияләү Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.";

в) түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

"5. Республика спорт федерацияләренә карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшереп тору максатларында физик культура һәм спорт өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы республика спорт федерациясе тарафыннан уздырыла торган спорт чараларына һәм аның җитәкче органнары утырышларына үз вәкилләрен җибәрергә мөмкин.";

3) түбәндәге эчтәлекле $10^1$ статья өстәргә:

"$10^1$ статья. **Республика спорт федерацияләренең хокуклары һәм бурычлары**

Республика спорт федерацияләренең хокуклары һәм бурычлары Федераль закон тарафыннан билгеләнә.";

4) 12 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ статья өстәргә:

"$1^1$. Волонтерларга компенсация түләүләре бирү һәм аларны матди-техник яктан тәэмин итү шартлары, тәртибе һәм нормалары Федераль закон тарафыннан билгеләнә.";

б) 14 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

"Татарстан Республикасы территориясендә халыкара спорт чараларын уздыруга, шул исәптән мондый чараларны уздыру хокукы өчен конкурста катнашуга гаризалар җибәрү физик культура һәм спорт өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә спортның тиешле төре буенча гомумроссия спорт федерациясе тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.";

5) 5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле $26^1$ статья өстәргә:

"$26^1$ статья. **Татарстан Республикасы спорт җыелма командаларын формалаштыру**

1. Спортның тиешле төре (төрләре) буенча Татарстан Республикасы спорт җыелма командаларына кандидатлар исемлекләре ел саен республика спорт федерацияләре тарафыннан төзелә һәм физик культура һәм спорт өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан раслана.

2. Регионара һәм гомумроссия спорт ярышларында катнашу өчен Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары спортның тиешле төре (төрләре) буенча Татарстан Республикасы спорт җыелма командаларына кандидатларның тиешле

исемлегенә кертелгән затлар арасыннан республика спорт федерацияләре тарафыннан төзеләләр һәм физик культура һәм спорт өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан расланалар.

3. Татарстан Республикасы спорт җыелма командаларына кандидатлар исемлекләрен төзүнең гомуми принциплары һәм критерийлары, аларны раслау тәртибе физик культура һәм спорт өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан билгеләнә.";

6) 29 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

"3. Чит дәүләтләрдә медицина яисә фармацевтика белеме алган һәм чит дәүләтләрнең физик культура-спорт оешмалары тарафыннан медицина белгечләре сыйфатында тәкъдим ителгән затларның медицина ярдәме күрсәтүе Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 18 июне
№ 49-ТРЗ